


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 9 (24) 13 МАЯ 2010



# В дружбе и единстве

**Знаменательное событие состоялось 28 апреля в селе Асекеево. В Доме культуры открыла свою работу Седьмая конференция татарской национально-культурной автономии района. На это мероприятие прибыли все шестьдесят избранных делегатов.**



Много было гостей, в том числе председатель духовного управления мусульман области, муфтий Абдулбари Хайруллин, один из руководителей региональной татарской автономии Вахит Шафеев, председатель ТОЦ «Туган тел» Бугурuслана Хамзя Газизов, председатель объединения «Туган тел» Похвистневского района Самарской области Расих Латыпов и другие.

На конференции присутствовал и выступил глава администрации Асекеевского района Николай Макаров.

Отчетный доклад сделал председатель ТНКА Ильдус Давлятов. (Вариант доклада на татарском языке мы публикуем сегодня на второй странице). За три года сделано много добрых и полезных дел. Выступившие в прениях поддержали участников конференции в этом мнении. В результате вышел спор, каким признать работу автономии: хорошим или удовлетворительным. Но регламент признает лишь слово «удовлетворительное».

На конференции избран новый состав совета ТНКА. Совет, на первом заседании, вновь избрал своим председателем Ильдуса Ядкаровича Давлятова.

Особо надо отметить атмосферу, которая царила на конференции. И татары, и русские гости говорили о дружбе и единстве во благо России.

По окончании конференции, И. Давлятов наградил от имени ТНКА ветеранов войны и труда.

**На фото:** гость конференции муфтий хазрат А.Хайруллин.

# ВЕТЕРАННАРГА КУАНЫЧЛЫ КҮРЕНЕШЛӘР



**Безнең Әсәкәй районында Бөек Җиңүнең 65 еллыгы якынайган саен ыгы-зыгы әзерлеге кызганнан кыза бара. Төрле мәдәният чаралары мәктәпләрдә, китапханәләрдә, мәдәният йортларында үткәрелә. Сугыш ветераннарын, бу әфәтле елларда тылда эшләгән апаларны төрле кичәләргә чакырып, аларның Бөек Җиңүгә керткән бәһасыз өлешләрен киләчәк буынга күрсәтү изге максат.**

Әсәкәй район милли-мәдәният мөхтәрияте дә бу чараларда актив катнашты. Татар ветераннарына игътибар йөзеннән «Туган як» газетына бүләк квитанциялар таратылды, конференциягә килгән ветеран делегатларына бүләкләр тапшырылды.

Ә 5-нче май көнне Әсәкәй районы сугыш ветераннары Татарстан Президенты Рөстәм Миннехановтан бүләкләр алдылар.

Бөек Җиңүгә багышлап махсус бизәлгән әчене затлы деликатеслар салынган 26 тартманы, район милли-мәдәният мөхтәрияте советы әгъзалары хөрмәтле ветераннарыбызны киләчәк бәйрәм белән котлап һәрберсенең өенә илтеп барып бирделәр Президент күчтәнәчен.

Бүләкләр районның һәрбер авылындагы ветераннарга да өләшенде. Әсәкәй авылының 10 ветераны бүләкләнде. Алар арасында сугышның башыннан азагына кадәр булган Шамгидаров Яхия абый күкрәге тулы орден, медальләр. Шулай ук 93 яшьлек ветеран Габдулла абый Шавалиев, Яңа Солтангол авылының сугыш ветераны Мәликә апа Гиззатуллина һәм башка хөрмәтле милләттәшләребез рәхмәтләрен әйтеп күчтәнәчләрне кабул иттеләр.

Бүләкләрне безнең Әсәкәй районы милли-мәдәният мөхтәрияте рәисе Илдус Давлятов Казанга барып алып кайтты. Шулай ук аңа күрше Богырыслан районы татар ветераннарына да 23 тартма бүләкләр биреп кайтарганнар. 5-нче май көнне алар безгә килеп үзләренә тиешле затлы тартмаларны алып киттеләр. Бу әлбәттә Татарстан Президенты тарафыннан булган бик әһәмиятле дә, шатлыклы да акция. Ветераннарыбызга мондый куанычлы күренешләр ешрак булсын иде дигән теләк, уйлар белән, татар активистлары бурычларын үтәп, кичке якта өйләренә таралыштылар.

Балалар китапханә мөдире Халисә Тавеева.

**На фото:** ветеран войны Я.Шамгидаров.

# Мәңге сүнми торган хәтер

Пономаревка районы Науруз авылыннан 332 ир-егет туган якларыннан, сөйгән ярларыннан аерылып фронтка киткәннәр. Сугыш кырындагы хәбәрләрне тылдагылар солдат хатлары аша гына белгәннәр, алар якыннарының исәнлек хатларын түземсезлек белән, тилмереп көтеп торган. Андый хат килү зур бәхет, зур шатлык булган. Хатны алгач, саклык белән генә төреп, югалмаслык урынга куйганнар һәм аларның кайберләре безнең көннәргә кадәр сакланган. Бүген дә без саргаеп беткән бу хатларны укып, авыр сугыш елларын искә төшерәбез.

«Бер кайтмасак, бер кайтырбыз», — диеп язсалар да, дошманны җиңеп туган якларга кайту 186 авылдашыбызга насыйп булмады. Алар Туган илебезнең төрле почмакларында, ят җирләрдә мәңгелеккә ятып калдылар, туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмадылар. Кара пичәтле коштеледәй кәгазь кисәкләре бәгырьләрне өзеп, күпме авылдашларны канлы яшь түктерде. Авылыбызның уртасында Бөек Җиңүнең 35 еллыгында сугышта һәлак булучы авылдашларыбызга һәйкәл куелды. Шулай итеп авылдашларыбыз таш сын булып туган авылыбызга мәңге яшь булып әйләнеп кайттылар. Корбан булган ил уллары безнең хәтердә мәңге.

Хәзерге көндә Бөек Ватан сугышында катнашкан 10 ветеранбыз исән.

1. ВАЛИШИН Ахмәтзия Гафүтдин улы.
2. ГАБДРАКИПОВ Заки Габдракип улы.
3. КАМАЛУТДИНОВ Зия Гизетдин улы.
4. КАМАЛУТДИНОВ Сәяфүтдин Хайрүтдин улы.
5. КАДЫРОВ Мөнир Нуртдин улы.
6. МИНИБАЕВ Мингали Муллагали улы.
7. МАХМУТОВ Мавлетгали Мөхәммәди улы.
8. НИГМАТУЛЛИН Махмут Насып улы.
9. ШАЙДУЛЛИНА Мүнәзия Хәйрулла кызы.
10. ШАГИАХМЕТОВ Гариф Шәрип улы.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгына карата үткәрелгән хәтер кичәләрендә мәктәп укучылары ветераннар белән очрашалар. Ветеран солдатларыбыз укучыларга кайларда сугышуларын, үзләренең кичергән авырлыклары турында сөйлиләр. Аларның сөйләве гади, әмма аларда дөреслек. «Җәһәннәм уты астында үзеңнең исән калуыңны, дошманны җиңүеңне уйлыйсың да мин бәхетле, дисең», — дилэр алар. «Бу сугыш кыйммәткә төште, шуңа күрә яулаган тынычлыкны, матурлыкны саклау сезнең бурыч», — диеп дәвам итәләр үзләренең сүзләрен. Бөек Җиңү алу хакына күрсәткән батырлыклары безнең күңелебездә мәңге сакланыр!

Ветераннарга исәнлек — саулык, озын гомер телэп

**БАШИРОВА С.С.**
**Науруз авылы.**

## Ветеранам — «Туган як»

**Депутат Законодательного собрания Оренбургской области, председатель татарской национально-культурной автономии Асекеевского района Ильдус Давлятов подарил каждому ветерану Великой Отечественной войны из Асекеевского, Абдулинского, Матвеевского и Пономаревского районов подписку на газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» на второе полугодие 2010 года.**

**Абонементы на подписку вложены в поздравительные открытки и высланы по почте ветеранам на дом.**